**ГЛАВА РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631д.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел (факс): 8 84378 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 8 84378 4-74-98

**2023 елның 01 ноябре** **5 номер**

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегенең Рождествено торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегенең Рождествено торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 16 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Рождествено торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Рождествено авылы балалар мәйданчыгын төзү (материаллар сатып алу, транспортлау, килешү буенча эш өчен түләү)

-Рождествено торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм тоту (смета буенча юл төзү: вак таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Рождествено авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе: С.М. Гуцу**